# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Зеленодольск районы һәм Зеленодольск шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Зеленодольск районы һәм Зеленодольск шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 46-ТРЗ

"Татарстан Республикасы
Зеленодольск районы һәм Зеленодольск шәһәре буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Зеленодольск районы һәм Зеленодольск шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Зеленодольск муниципаль районының Әйшә, Бишнә, Большие Ключи, Олы Карагуҗа, Олы Җәке, Новопольский, Осиново һәм Раифа авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Заикин һәм Октябрь урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көньякка таба Заикин урамының күчәр сызыгы буйлап Ленин урамының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, көнчыгышка таба Ленин урамының күчәр сызыгы буйлап Чехов урамындагы 19 нчы йортка кадәр бара, аннары уңга борыла һәм, сул якта урнашкан йортларны кертеп, көньякка таба автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Кызыл урамындагы 32А йортның көньяк-көнбатыш почмагы янында Кече Кызыл һәм Кызыл урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, "Красная горка" бакчачылык ширкәте территориясен кертеп, көнбатышка таба Кече Кызыл урамының күчәр сызыгы буйлап, "Красная горка" бакчачылык ширкәте территориясен кертеп, "Красная горка" бакчачылык ширкәте территориясе коймасының төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньякка таба әлеге бакчачылык ширкәте коймасының көнбатыш ягы буйлап Зеленодольск – Волжск тимер юлына бүлеп бирелгән полоса белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көнчыгышка таба Зеленодольск – Волжск тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап Зеленодольск – Свияжск тимер юлы белән тимер юллар тоташкан җиргә кадәр бара, алга таба, сул якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, көнбатыш юнәлештә Зеленодольск – Свияжск тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап Башкала урамы белән кисешкән җирдә урнашкан тимер юл аркылы чыгу урынына кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көньяк-көнбатышка таба автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Озерная урамындагы 48 нче йортның төньяк почмагы янында

урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба, Озерная урамындагы 50А йортны кертеп, көньякка таба Озерная урамындагы 48 һәм 50А йортлар арасындагы автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Футбол урамындагы 10 нчы йорт янындагы тимер юл тармагы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, сул якта урнашкан сәнәгать зонасы территориясен кертеп (Футбол урамы, 10), көньяк юнәлештә тимер юл тармагына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш ягы буйлап Идел елгасы ярына кадәр бара, аннары шул ук юнәлештә су саклау зонасы территориясе коймасы буйлап яр полосасына кадәр уза һәм алга таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең көньяк чигенә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм көнчыгышка таба "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең "Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге белән чиге буйлап "Зеленодольск шәһәре", "Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы", Әйшә һәм Свияжск (Зөя) авыл җирлекләре муниципаль берәмлекләренең чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан тоташу ноктасына кадәр уза, алга таба төньякка таба "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең Әйшә авыл җирлеге белән чиге буйлап Башкала урамының күчәр сызыгы белән (Казан – Зеленодольск автомобиль юлы) кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба суд участогы чиге, сул якта урнашкан урман посадкасын кертеп, көньяк-көнбатышка таба Башкала урамының күчәр сызыгы буйлап Королев урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, төньяк-көнбатышка таба Королев урамының күчәр сызыгы буйлап Королев урамындагы 14 нче йортның көньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм, Королев урамындагы 12 нче йортны һәм Комаров урамындагы 2, 2А йортларны кертеп, көнбатыш юнәлештә Королев урамындагы 14, 16 һәм 16А йортларның көньяк-көнчыгыш ягы буйлап гаражлар комплексының көньяк-көнчыгыш почмагына кадәр уза, алга таба, Комаров урамында урнашкан йортларны кертеп, шул ук юнәлештә гаражлар комплексының көньяк ягы һәм зират территориясе коймасы буйлап Казан – Йошкар-Ола тимер юлына бүлеп бирелгән полоса белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньякка таба Казан – Йошкар-Ола тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап Октябрь урамы белән кисешкән җирдә урнашкан автомобиль күперенә кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, көнбатышка таба Октябрь урамының күчәр сызыгы буйлап Заикин урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза.

**3 нче суд участогы**

3 нче суд участогы чигенә "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Гагарин һәм Энгельс урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көньякка таба Гагарин урамының күчәр сызыгы буйлап Ленин урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көнчыгышка таба Ленин урамының күчәр сызыгы буйлап Яшьлек урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп ("Авангард" стадионы территориясе),

төньякка таба Яшьлек урамының күчәр сызыгы буйлап Карл Маркс урамындагы 57Б йорт ("Чыршыкай" балалар бакчасы) территориясе коймасының көньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, Карл Маркс урамындагы 57А йортны кертеп, шул ук юнәлештә әлеге йорт территориясе коймасының көнбатыш ягы буйлап Карл Маркс урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, көнбатышка таба Карл Маркс урамының күчәр сызыгы буйлап Карл Маркс урамындагы 44 нче йортның көньяк-көнбатыш почмагы янында Тынычлык урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, төньякка таба Тынычлык урамының көнчыгыш ягы буйлап Гоголь урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, көнбатышка таба Гоголь урамының күчәр сызыгы буйлап Татарстан урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, төньякка таба Татарстан урамының күчәр сызыгы буйлап дәүләт урман фондының урман массивы чигенә кадәр бара, алга таба, сул якта урнашкан йортларны һәм урман массивы территориясен кертеп, шул ук юнәлештә Татарстан урамының дәвамы буларак уза торган автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең төньяк чигенә кадәр уза, алга таба көнбатыш юнәлештә "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең Әйшә авыл җирлеге белән чиге буйлап Рогачев урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр бара, аннары суд участогы чиге сулга борыла һәм, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көнчыгыш юнәлештә Рогачев һәм Энгельс урамнарының күчәр сызыклары буйлап Гагарин урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза.

3 нче суд участогы чигенә "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең көньяк өлешендәге сәнәгать-коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге Фабрика һәм Төзүчеләр урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, сул якта урнашкан сәнәгать зонасы территориясен кертеп, төньякка таба Фабрика урамының күчәр сызыгы буйлап Яңа төзелеш урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба көнбатышка таба Яңа төзелеш урамының күчәр сызыгы буйлап "А.М. Горький исемендәге Зеленодольск заводы" ачык акционер җәмгыятенең (Завод урамы, 5) 4 нче керү-чыгу урыны янында урнашкан җәяүлеләр күперенә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм, Яңа төзелеш урамындагы 3В йортны кертеп, төньякка таба Зеленодольск – Волжск тимер юлына бүлеп бирелгән полоса белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көнбатышка таба Зеленодольск – Волжск тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап Яңа төзелеш, Вокзал яны урамнары һәм Зеленодольск – Волжск автомобиль юлы кисешкән җирдә урнашкан тимер юл аркылы чыгу урынына кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньякка таба Вокзал яны урамындагы 5 нче йортның (1 нче корпус) төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, "Идел буе фанера-мебель комбинаты" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять территориясен кертеп, шул ук юнәлештә "Серго исемендәге завод" җитештерү берләшмәсе" федераль дәүләт унитар предприятиесенең (Вокзал яны урамы, 4) һәм "Идел буе фанера-мебель комбинаты" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең (Вокзал яны урамы, 5) сәнәгать

мәйданчыклары территорияләрен аерып торучы койма буйлап Идел елгасының уң як ярындагы яр буе полосасына кадәр бара, алга таба көньяк-көнчыгышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан көньяк чигенә кадәр бара, алга таба көнчыгышка таба "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең "Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге белән чиге буйлап тимер юл күперенең көнбатыш чиге белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары суд участогы чиге сулга борыла һәм төньякка таба тимер юл күперенең көнбатыш ягы буйлап Идел елгасының уң як ярындагы яр буе полосасына кадәр уза, алга таба көнбатыш юнәлештә яр буе полосасы буйлап "А.М. Горький исемендәге Зеленодольск заводы" ачык акционер җәмгыяте (Завод урамы, 5) территориясе коймасы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньякка таба койманың көнчыгыш ягы буйлап 1 нче Төзелеш тыкрыгы һәм Яр буе урамының күчәр сызыклары кисешкән җир янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә 1 нче Төзелеш тыкрыгының күчәр сызыгы буйлап Төзелеш урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба көнчыгышка таба Төзелеш урамының күчәр сызыгы буйлап Фабрика урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр бара.

**4 нче суд участогы**

4 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Зеленодольск муниципаль районының Васильево шәһәр тибындагы поселогы һәм Октябрь авыл җирлеге.

**5 нче суд участогы**

5 нче суд участогы чигенә "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Заикин һәм Октябрь урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, так якта урнашкан йортларны кертеп, көньякка таба Заикин урамының күчәр сызыгы буйлап Ленин урамының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көнбатышка таба Ленин урамының күчәр сызыгы буйлап Яшьлек урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, төньякка таба Яшьлек урамының күчәр сызыгы буйлап Карл Маркс урамындагы 57Б йорт ("Чыршыкай" балалар бакчасы) территориясе коймасының көньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә әлеге йорт территориясе коймасының көнбатыш ягы буйлап Карл Маркс урамындагы 57А йортның көнчыгыш ягыннан Карл Маркс урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көнбатышка таба Карл Маркс урамының күчәр сызыгы буйлап Карл Маркс урамындагы 44 нче йортның көньяк-көнбатыш почмагы янында Тынычлык урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм, так якта урнашкан йортларны кертеп, төньякка таба Тынычлык урамының көнчыгыш ягы буйлап Гоголь урамының күчәр сызыгы белән кисешү

ноктасына кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көнбатышка таба Гоголь урамының күчәр сызыгы буйлап Татарстан урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, төньякка таба Татарстан урамының күчәр сызыгы буйлап дәүләт урман фондының урман массивы чигенә кадәр бара, алга таба, уң якта урнашкан урман массивы территориясен кертеп, шул ук юнәлештә Татарстан урамының дәвамы буларак уза торган автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең төньяк чигенә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең Әйшә авыл җирлеге белән чиге буйлап Казан – Йошкар-Ола тимер юлына бүлеп бирелгән полоса белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба суд участогы чиге көньяк юнәлештә Казан – Йошкар-Ола тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап Октябрь урамы белән кисешкән җирдә урнашкан автомобиль юлы күперенә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көнбатышка таба Октябрь урамының күчәр сызыгы буйлап Заикин урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр бара.

5 нче суд участогы чигенә "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең көньяк өлешендәге сәнәгать-коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге Зеленодольск – Волжск һәм Зеленодольск – Свияжск тимер юллары чатында урнашкан ноктадан алып, сул якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, көнбатышка таба Зеленодольск – Свияжск тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап "А.М. Горький исемендәге Зеленодольск заводы" ачык акционер җәмгыятенең (Завод урамы, 5) 4 нче керү-чыгу урыны янында урнашкан җәяүлеләр күперенә кадәр уза, аннары сулга борыла һәм, Яңа төзелеш урамындагы 3Б йортны кертеп, көньякка таба Яңа төзелеш урамының күчәр сызыгы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көнчыгышка таба Яңа төзелеш урамының күчәр сызыгы буйлап Фабрика урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр бара, алга таба көньякка таба Фабрика урамының күчәр сызыгы буйлап Төзелеш урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба, сул якта урнашкан йортларны кертеп, көнбатышка таба Төзелеш урамының күчәр сызыгы буйлап 1 нче Төзелеш тыкрыгы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба көньякка таба 1 нче Төзелеш тыкрыгының күчәр сызыгы буйлап Яр буе урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба 1 нче Төзелеш тыкрыгының дәвамы буларак шул ук юнәлештә "А.М. Горький исемендәге Зеленодольск заводы" ачык акционер җәмгыятенең сәнәгать мәйданчыгы территориясе коймасы буйлап Идел елгасының уң як ярындагы яр буе полосасына кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә яр буе полосасы буйлап тимер юл күперенә кадәр уза, алга таба, сул якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, гомуми юнәлештә төньяк-көнчыгышка таба Зеленодольск – Свияжск тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап Зеленодольск – Волжск тимер юлы белән тимер юллар тоташкан җирдә урнашкан ноктага кадәр бара.

**6 нчы суд участогы**

6 нчы суд участогы чигенә "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Гагарин һәм Энгельс урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, так якта урнашкан йортларны кертеп, көньякка таба Гагарин урамының күчәр сызыгы буйлап Ленин урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, көнчыгышка таба Ленин урамының күчәр сызыгы буйлап Чехов урамындагы 19 нчы йортка кадәр бара, аннары уңга борыла һәм, уң яктагы йортларны кертеп, автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Кызыл урамындагы 32А йортның көньяк-көнбатыш почмагы янында Кече Кызыл һәм Кызыл урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба көнбатышка таба Кече Кызыл урамының күчәр сызыгы буйлап "Красная горка" бакчачылык ширкәте территориясе коймасының төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньякка таба бу бакчачылык ширкәте коймасының көнбатыш ягы буйлап Зеленодольск – Волжск тимер юлына бүлеп бирелгән полоса белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба көнбатышка таба Зеленодольск – Волжск тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап Вокзал яны, Яңа төзелеш урамнары һәм Зеленодольск – Волжск автомобиль юлы кисешкән җирдә урнашкан тимер юл аркылы чыгу урынына кадәр бара, аннары сулга борыла һәм көньякка таба Вокзал яны урамындагы 5 нче йортның (1 нче корпус) төньяк-көнбатыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә, "Серго исемендәге завод" җитештерү берләшмәсе" федераль дәүләт унитар предприятиесе территориясен кертеп, "Серго исемендәге завод" җитештерү берләшмәсе" федераль дәүләт унитар предприятиесенең (Вокзал яны урамы, 4) һәм "Идел буе фанера-мебель комбинаты" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең (Вокзал яны урамы, 5) сәнәгать мәйданчыклары территорияләрен аерып торучы койма буйлап Идел елгасының уң як ярындагы яр буе полосасына кадәр уза, алга таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап, борынны һәм утрауны кертеп, көньяк-көнчыгышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең көньяк чигенә кадәр бара, аннары уңга борыла һәм көнбатышка таба "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең "Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге белән чиге буйлап "Зеленодольск шәһәре", "Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлекләре һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан тоташу ноктасына кадәр уза, алга таба төньякка таба Татарстан Республикасының административ чиге буйлап "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлеге, Әйшә авыл җирлеге һәм Марий Эл Республикасы чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан тоташу ноктасына кадәр уза, алга таба "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең Әйшә авыл җирлеге белән чиге буйлап Рогачев урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр бара, аннары суд участогы чиге уңга борыла һәм, так якта урнашкан йортларны кертеп, көнчыгыш юнәлештә Рогачев һәм Энгельс урамнарының күчәр сызыклары буйлап Гагарин урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза.

## 7 нче суд участогы

7 нче суд участогы чигенә "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең көнчыгыш чиге һәм Башкала урамының күчәр сызыгы кисешкән җирдә (Казан – Зеленодольск автомобиль юлы) урнашкан ноктадан алып, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, көньяк-көнбатышка таба Башкала урамының күчәр сызыгы буйлап Королев урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, төньяк-көнбатышка таба Королев урамының күчәр сызыгы буйлап Королев урамындагы 14 нче йортның көньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр бара, аннары сулга борыла һәм, Королев урамындагы 14, 16 һәм 16А йортларны кертеп, көнбатыш юнәлештә Королев урамындагы 12 нче йортның төньяк-көнбатыш ягы һәм Комаров урамындагы 2, 2А йортлар буйлап гаражлар комплексының көньяк-көнчыгыш почмагына кадәр уза, алга таба, гаражлар комплексын һәм зират территориясен кертеп, шул ук юнәлештә гаражлар комплексының көньяк ягы һәм зират территориясе коймасы буйлап Казан – Йошкар-Ола тимер юлына бүлеп бирелгән полоса белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба төньякка таба Казан – Йошкар-Ола тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлеге чигенә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көнчыгыш юнәлештә "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең Әйшә авыл җирлеге белән чиге буйлап Башкала урамының күчәр сызыгы белән кисешү ноктасына (Казан – Зеленодольск автомобиль юлы) кадәр уза.

7 нче суд участогы чигенә "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең көньяк өлешендәге сәнәгать-коммуналь зона территориясендә урнашкан басу аша кишәрлек керә, аның чиге Озерная урамындагы 48 нче йортның төньяк почмагы янында урнашкан ноктадан алып, уң якта урнашкан сәнәгать зонасын кертеп (Озерная урамы, 48), көньякка таба Озерная урамындагы 48 һәм 50А йортлар арасындагы автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап Футбол урамындагы 10 нчы йорт янында тимер юл тармагы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба шул ук юнәлештә тимер юл тармагына бүлеп бирелгән полосаның көнбатыш ягы буйлап Идел елгасы ярына кадәр бара, аннары су саклау зонасы территориясе коймасы буйлап яр буе полосасына кадәр уза һәм Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең көньяк чигенә кадәр уза, аннары уңга борыла һәм көнбатышка таба "Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлегенең "Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге белән чиге буйлап тимер юл күперенең көнбатыш чиге белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары суд участогы чиге төньякка таба тимер юл күперенең көнбатыш ягы буйлап Идел елгасының уң як ярындагы яр буе полосасына кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан сәнәгать-коммуналь зона территориясен кертеп, уртак юнәлештә төньяк-көнчыгышка таба Зеленодольск – Свияжск тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап Башкала урамы белән кисешкән җирдә урнашкан тимер юл аркылы чыгу урынына кадәр бара, алга таба көньяк-көнбатышка таба борыла һәм автомобиль юлы буйлап

Озерная урамындагы 48 нче йортның төньяк почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза.

## 8 нче суд участогы

8 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Акъегет, Олы Ачасыр, Олы Ходяш, Олы Шырдан, Күгәй, Күгеш, Мамадыш-Әкил, Мизиново, Мулла Иле, Түбән Урысбага, Норлат, Рус Әҗиле, Свияжск (Зөя) һәм Өтәшкә авыл җирлекләре.